Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

ЧАЯН



6

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮНЬ * 2021 * КАЗАН

Валерий ТАРАСЕНКО



«Всё покупается и продается,
Жизнь откровенно над нами смеется.
Мы негодуем, мы возмущаемся,
Но продаемся и покупаемся».

Гомәр hӘЙЯМ

ДӨРЕСЕН ӘЙТСӘК:

Бу балалар – сез төзегән
Җәмгыять корбаннары...
Ә без, ә без шул тормышка
Гамсезлек кылганнары.

Карап торып ил җимерттек,
Дошман булдык дусларга,
Белә торып "алкашлар"га
Рөхсәт бирдек таларга.

Калды картлар пенсиянең
Сәдака хәтлесенә.
Яшьләр качты чит илләргә,
Эшче – эт типкесендә.

Әхлак бетте, тел тигзәләр
Алласы-мулласына.
Зур түрәләр сарай сала
Халкының акчасына.

Олигархлар күп үрчеде,
Юк иде элек алар.
Монда тормый, читтә яшәп
Этлек эшләп яталар.

Керде илгә начар вирус,
Америка модасы.
Анда ниләр кылансалар –
Хәзер монда барысы.

Телевизорда үтереш –
Атыш, урлаш һәм ришвәт.
Тәрбия юк, онытылды,
Акчаң булса – шул әйбәт.

Урамнарда ни телисең
Шуны эшләргә ярый.
Әнә берәү мылтык тоткан –
Мәктәпкә, ахры, атлый.

Берәүнең юк анда гаме,
Сора: "Кая барасың?"
Атып китә бит үзеңне,
Кем ул, белми каласың.

Йә берәүнең баласыдыр,
Кисәтергә ярамый.
Утыртырлар тик үзеңне,
Суд дөреслек карамый.

Ә балалар, ә балалар...
Кан йотып сыкраулары... –
Күп үтәргә туры килер,
Ахры бу сынауларны.

Алмаз ХӘМЗИН

Анатолий НЫРОВ



ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Чираттагы тапкыр күңелсез нәтиҗәгә килдем: безнең халыкта экологик тәрбия бөтенләй юк икән. Уйлап карагыз. Күптән түгел безнең ишегалдында чүпне аерым җыю өчен контейнерлар куйдылар. Аларга хәтта сурәтләр дә ясап куелган – кайсына нинди ен ташларга. Ә йортларда яшәүчеләр элеккечә бөтен чүпне бергә өяләр...

М. МИФТАХОВА

КАЗАН

Шомбай аганы укучыбызның хаты бик кызыксындырды.

– Минемчә, ул хаклы түгел, – диде аксакал. – **Безнең халыкта экологик традицияләр элек-электән килә. Исегездәме, элек чүп чиләгенең төбенә полиэтилен урынына кәгазь җәяләр иде, сөтне пыяла банкаларга бушатып саталар, ә шешә-банкаларны кабул итү нокталарына илтеп тапшыралар иде... Бүгенге экологларга бу турыда хыялланасы гына кала!**

Гамил АФЗАЛ

МИН КЕМ ИКӘН...

...Эшләр бара алга таба,
Кәгазь тулы портфель селкәм.
Зур начальник кызын тага;
Мин кем икән, мин кем микән!

Ары барсам, бире килсәм,
"Фәләнев кияве" дисәм,
Җылы урын, оклад исән;
Мин кем микән, мин кем микән!

Тузлар беләи гүләйт итәм,
Торырга Мәскәүгә күчәм,
Су урынына коньяк эчәм;
Мин кем микән, мин кем микән!

Алтын таулар вәгъдә итәм,
Киләм-китәм, туйны көтәм,
Телдән төшми "җаным", "иркәм",
Мин кем микән, мин кем микән!

Бүген иртән йөгереп килсәм,
Начальниктан җилләр искән –
Креслосыннан очып төшкән, –
Мин кем идем – мин шул икән.



Вячеслав ШИЛОВ

Василий АЛЕКСАНДРОВ



КОТЫРГАН ДУСЛАР

"Эт кешенең дусты" дигән сүзләр безгә балачактан таныш. Ләкин соңгы вакытларда алар арасыннан кара мәче узды бугай. Дүрт аяклы дусларыбыз чылбырдан ычкынган диярсең – алар өерләргә җыелып, кешеләргә һөҗүм итәләр, аерым ишегаллары һәм урамнар гына түгел, ә зур төбәкләр өчен дә җитди уңайсызлыклар тудыралар. Узган ел эчендә генә Татарстан буенча 10 мең кеше тешләнгән. Һәм бу гаҗәп түгел, чөнки республикабыз монда да алдынгы сафларда – ул хуҗасыз этләр саны буенча илдә беренче урынны тота. Туган җиребезнең авылшәһәрләре һәм юллары буйлап 24 мең дүрт аяклы зат йөри. Бу сан якынча, әлбәттә – туу күрсәткечләрен арттыру өчен аларга ана капиталы кирәк түгел бит.

Әлегә кадәр этләр тарафыннан аяклары тешләнгән һәм ыштаннары ертылган гражданнарга әллә ни игътибар итмиләр иде: кем белән булмас – төзәлер әле, имеш. Әмма соңгы вакытта кешеләргә ау киң колач алды. Мисал өчен, Биектау районының Шигали авылында эт өере ир кешегә һөҗүм иткән. Әгерҗе районында бер хатынны тешләгәннәр. Арча районында яшәүче егеткә исә бәхет елмаймаган. Ул хайваннардан заман технологияләре – ноутбук салынган сумка ярдәмендә котылган. Ярый әле, гаджет зур һәм авыр булган. Егетнең күргән зыяны бераз курку, ертылган ыштан һәм ватылган ноутбук белән генә чикләнгән.

Еш кына җитди очраклардан соң башкарма комитетлар тарафына чара күрү турында мөрәҗәгатьләр кертелә. Кайчагында җинаять эшләре дә кузгатыла. Гадәттә, барча мәшәкатьләр җирле хакимияткә йөкләнә: хайваннарны стерилизацияләү турындагы законны үтәү – аларның турыдан-туры бурычы. Ләкин чиновниклар белдерүенчә, моның өчен каралган акча җитми...

Яшел Үзән районы Осиново авылында 11 яшьлек малай белән булган вакыйгадан соң (аны, бәхеткә, котырып калдылар) гамәлдәге хуҗасыз этләрне тоту, стерилизация, вакцинация турындагы таләпләрнең, йомшак итеп әйткәндә, үйланылмаган булуы ачыкланган. Эт колагына беркетелгән сары йә яшел төстәге алканың аның кешеләргә карата дустанә мөнәсәбәтен белдерә алмый икән. Өстәвенә, этнең агрессивлык дәрәҗәсен нәрсә буенча билгеләргә – өрү көче буенчамы, әллә тешләнгәннәр саны буенчамы? Һәм иң гаҗәп нәрсә: стерилизация үткән этләрнең яңа туган көчекләр ияртеп йөрү очраклары теркәлгән. Бу нәрсә – эволюциянең яңа стадиясеме, әллә бюджет суммаларын үзләштерүнең яңа ысулымы? Бу йомгакның очына чыгу да артык булмас иде...

Көтелмәгән нәрсә: бу хәлдә әлеге дә баягы "чүп реформасы" да үз ролен уйнаган. Тыгыз капкачлы яңа чүп баклары кулланышка кертелү сәбәпле, хуҗасыз этләр гадәттәге туклану урыннарыннан мәхрүм калганнар. Ә ачлык ул эт холкын да танымаслык итеп үзгәртә ала.

Татарстанда гына түгел, Россиянең башка өлкәләрендә дә охшаш хәл хөкем сөрә. Бөтен ил буенча котырынган өерләр акрын гына кешенең яшәү мохитен яулый. Күрше Башкортстанда, мәсәлән, үз йорты каршында 4 яшьлек нәни тешләнгән. Пермьдә этләр көтүе 58 яшьлек хатынга ташланган, ә Ухта шәһәрендә чыгырыннан чыккан хайваннар ир белән хатынга һөҗүм иткән...

Әмма, ни дисәк тә, хәлне үзгәртү юнәлешендә чаралар күрелә. Һәрхәлдә, Татарстанда. Бездә, кешеләргә ауны туктату максаты белән, хуҗасыз хайваннар өчен приютлар булдыру һәм стерилизация эшләрен контрольдә тоту өчен 2,2 миллиард сум каралган. Бу "эт проблемасын" хәл итәргә ярдәм итәрме – монысын вакыт күрсәтер. Планнар буш сүз генә булып калмасын иде...

Людмила САФИУЛЛИНА



Александр АЛЁШИН

Вячеслав ШИЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Виктор БОГОРАД





• • •

– Чын ирләрне аяз көнне чыра яндырып эзләсәң дә табалмыйсың!

– Бәлки, төнлә ут кабызмый гына эзләп карарга дыр?

• • •

Элеккеге бизнес: башта кешегә нәрсә кирәген бел, һәм моны ничек эшләргә икәнен уйла.

Хәзерге бизнес: теләсә нәрсә уйла, шуннан соң сатып алучыңны бу нәрсәнең аңа кирәклегенә ышандыр.

• • •

– Әгәр вокзалга барып, минем тёщамны каршы алсаң, мин сиңа 500 сум бирермен.

– Ә ул килмәсә?

– Ул чагында мең сум!

• • •

Быел диңгезгә, коронавирус булу сәбәпле, бармыйм. Моңа хәтле акчам булмау аркасында бармаган идем.

• • •

Ире идәндәге үлчәүгә баскан да корсагын эчкә тарткан.

Хатыны:

– Корсагыңны үлчәүгә баскач тартып тору мәгънәсез!

– Мин бит цифрларны күрергә телим.

• • •

Кешелеккә чыкканнарны халык арасында күрмәссең.

• • •

– Әлү, исәнмесез. Мин белдерү буенча шалтыратам – сезгә сәркатип-референт кирәк икән.

– Әйе, ул урын әлегә буш.

– Үзем турында ниләр язарга? Һөнәремне әйтергәме, телләр белүемнеме, компьютер белән эш итә белүемнеме?..

– Бернәрсә дә кирәкми. Купальниктан төшкән фотографиягезне җибәрегез, ә калганын без үзебез ачыкларбыз.

• • •

Берәү дусты янына киңәш сорап килгән: өйләнергәме, өйләнмәскәме?

– Өйләнсәң дә, өйләнмәсәң дә, барыбер үкенәчәксең, – дип җавап биргән дусты.

• • •

– Ни өчендер, хатынының "шәп ир" дигән сүзеннән соң "тиеш" сүзе бара.

Рушания ГЫЙЛӘҖЕВА

МУНЧА БУТАЛЫШЫ

Бу хәл Яңа Кәшер авылында була.

Бер урамда яшәүче ике күршенең исеме Гөлчирә икән. Бу ике гаиләнең дә мунчасы бар. Янәшәләрендә генә мунча салырга өлгереп җитмәгән Нурулла һәм Гөлназ яши. Алар йә Илдус хатыны Гөлчирә мунчасын, йә икенче йорттагы Гөлчирә мунчасын ягалар. Бервакыт җәйнең бик ямьле аяз җылы көнендә Илдус белән Гөлчирәгә кунаклар килеп төшә. Алар барысы, җыелышып, ишегалдына чыгып, көлешеп сөйләшеп утыралар икән. Көтмәгәндә бәрәңге бакчасы сукмагыннан битборыны кызарып пешкән Нурулла килеп чыга. Ул үзенә, күзен текәгән хуҗабикәгә мөрәҗәгать итеп:

– Гөлчирә, хуш, рәхмәт, мунча хөрмәтенә, бик яхшы булды. Мунчаның кайнар суы бар иде, ләкин салкын суы гына булмады, – ди.

Бөтен кунаклар бернәрсә аңламыйча аптырашка кала.

Шул вакыт Нурулла кунаклар арасында утырган хатыны Гөлназны әрләргә керешә:

– Ә син нишләп мунчаны якканда кайнар су гына ташыдың, салкын су да ташып булмый идемени?..

Гөлназ, чак кына көлеп җибәрми калып, аклана башлый:

– Соң бит мин мунчаны Илдус Гөлчирәсенә түгел, икенче Гөлчирәләрдә яккан идем.

Чынлап та, Илдус Гөлчирәсе мунчасына кунакларының иң соңгысыннан Зәкия апа кереп, салкын суны бөтенләй бетереп чыккан була, ә Нурулла, мунчаларны бутап, ялгыш Илдус Гөлчирәсе мунчасына кергән, тик кайнар су белән генә юынып чыгарга мәҗбүр булган.

Яшәргә кызыграк булсын өчен, тормыш үзе шундый мәзәкләрне тудыра бугай.

Анастасия ВАСИЛЬЕВА





Илдар НӘФИЕВ

Ринат АБЗАЛОВ

ШИГЫРЬ ҮРГӘНДӘ...

Яңа уйлар, фикер тусын өчен,
Тынлык зарур, диләр, иҗатка.
Чумар өчен илһам дөньясына,
Чын ялгызлык кирәк ир-атка.
Минут саен колак итең ашап,
Теңкәләргә хатын тимәсен,
Үтүгемне рәтлә, тузан суырт,
Чүпне чыгар, ялкау, димәсен.

...Шагыйрь булсам, мин дә, ялгыз калып,
Туплар идем даһи фикерләр,
Ятар иде һәр кич кәгаземә
Менә дигән бөек шигырьләр;
Ялгызлыктан сихри көчләр алгач,
Янар иде очкын күземдә,
Һәм каләмем үзе язар иде,
Илаһи нур күреп йөземдә...

Тик шулай да, җаным-тәнем белән
Иҗат диңгезендә йөзгәндә,
Галәм белән бер дулкынга кереп,
Шигырь юлларымны үргәндә,
Җанны ярып искә төшәр иде
Күрше якта хатын йөргәне,
Йомшак кына ишегемне шакып,
Чәй кайнады, җаным, дигәне...



Василий ШИМБЕРЕВ

Эволюция

Эволюция күренешен, минемчә, солдат хезмәте мисалында карау уңайлырак. Армиягә әле бернинди мөнәсәбәте булмаган малайны, ягъни допризывникны алыйк. Үтә гади, оешып җитмәгән зат. Аңа гадәттә төрле көтелмәгән уйлар һәм гамәлләр хас. Ул хәтта фәнни тикшерену объекты булырга да лаек түгел.

Ә менә хезмәткә чакырылган егет, призывник – бу инде бөтенләй башка нәрсә. Аның башында ачык, төгәл фикерләр очраштыргалый. Анда инде акыл билгеләре – курку, кимсену һәм өмет кебек тойгылар бар. Болары сөйгән кызының аның кайтуын көтү-көтмәвенә бәйле, әлбәттә.

Ләкин армиягә алыну ул әле үзгәреш түгел, ә алгарышка этәргеч кенә. Әдәпле, әмма катгый этәргеч! Тик аңа бирешергә дә, бирешмәскә дә була. Монысы инде үзеңнән тора. Аның ысуллары җитәрлек. Шуңа күрә бу турыда артыгын сүз куертып тормаска да була...

Хәзер яңадан сүз башына – допризывникка кайтыйк. Ул – табигатьтә материаль тәңгәллеге булмаган, буш зат. Армия сүзлегендә аның өчен аерым сүз дә юк. Ул бары тик солдатның яралгысы – дөрес тәрбия нәтиҗәсендә генә купсанлы хезмәт баскычларын үтеп, башта – "дед"ка, ә аннары эволюциянең иң югары ноктасына – дембельгә, ә ахырда җәмгыять әгъзасы – Гражданинга әверелергә тиешле зат!

Ә менә кызы ул Гражданинны сагынып көтеп алырмы?.. Бу сорауга инде бернинди фән дә җавап бирә алмый.

Сергей АНДРИАНОВ



Александр АЛЁШИН



Абау!

СУГА АККАН МИЛЛИОННАР

Мөһим стратегик объект – Түбән Кама сусаклагычы тирәсендә җәнҗал кыза. "Түбән Кама сусаклагычын эксплуатацияләү идарәсе" федераль учреждениесе һәм "Патрон" шәхси саклау предприятиесе дамбаны тәүлек буе саклау турында килешенү төзегән булганнар. Бу җаваплы эшне 15 сакчы башкарырга тиеш булган, ә чынлыкта исә аларның саны алтыдан артмаган, алары да объектта сирәк-мирәк кенә күренеп киткән. Әмма хезмәт хакын бөтенесе дә тулысынча алып барган. Тикшерү эшләре тәмамлангач, елгыр егетләргә законсыз рәвештә 10 миллион сумнан артык акча күчерелгәне ачыкланган.

ЧЕМОДАН КАРАКЛАРЫ


Казан аэропортының алты хезмәткәре пассажирларның чемоданнарыннан әйбер урлауда капкан. Караклар эресен-вагын аерып тормаганнар. Аларда ноутбук, мобиль телефон, биш пар балалар кроссовкасы, ике шешә аракы һәм хәтта чәч бөдрәләтү җайланмасы да табылган. Урланган әйберләрнең гомуми бәясе йөз мең сум тәшкил иткән.

ТАШТАН – АКЧА

Чистай районы Аделша авыл җирлегенең элекке башлыгы буш урында акча ясарага өйрәнгән. Берзаман ул авыл өчен тоннасын 600 сумнан 700 тонна вак таш сатып алган, ә килешенүдә башка сумма – тонна өчен 700 сум күрсәтелгән булган. Аермасы җирле эшмәкәрең счёты аша чиновникның кесәсенә күчеп утырган. Авыл эшкуарының бизнес сәләтенә суд бәя бирәчәк.

ДАН КАЗАНУ ЫСУЛЫ

Казандагы 4 нче номерлы автотранспорт предприятиесенең ике ремонтчысы иҗтимагый челтәрдә дан казанырга булганнар. Аларга автобусның алгы пыяласын алыштырырга кушканнар. Иске пыяланы гадәти юл белән алу аларга күңелсез тоелгандыр, күрәсең – егетләр аны чүкеч белән ватып, гамәлләрен смартфонга төшергәннәр. Ләкин бу юл белән җәмгыять алдында күтәрелү барып чыкмаган – икесен дә хезмәт дисциплинасын һәм куркынычсызлык техникасын бозган өчен эштән чыгарганнар.



Александр БРЮХАНОВ

СӘЛАМӘТ БУЛЫГЫЗ!

Табибка бардым.

– Доктор, – дим, – муеныма нәрсәдер булды. Борыйм дисәң, шыгырдый башлый...

– Эштәндер бу, җанкисәгем, – диде табиб, муенымны капшап карагач. – Ничава, башыгызны җилкәгә батырыбрак йөрсәгез, бетәргә тиеш...

– Тагын әле сырт авырта, түзәрлек түгел...

Ул минем сыртыма карап алды.

– Әйе, ул сезнең бик шәптән түгел икән шул, – диде ул. – Бакчада күп эшлисездер. Ничә сутый инде?

– Алты, – дидем мин турыдан-туры.

– Шулай дип уйлаган идем дә. Мин сезгә бераз бөкрәебрәк йөрергә тәкъдим итәр идем, шулай итсәгез, авыртулар бетәргә тиеш...

– Бөкрәйсәм, эчем борчый башлый...

– Эч шундый нәрсә инде ул, бөтен кешенеке дә авырта, – дип тирән сулап куйды табиб. – Төрле юк-бар ашыйбыз, авызга алмаслык нәрсә эчәбез! Сезнең очракта бүксәне кул белән тотып йөрергә кирәк, авыртуы кимесен өчен...


– Тагын әле, аяк та сызлаштыргалый...

– Ә ул сезнең бала чактан ук сызлый торгандыр, әйеме? Футбол уйный идегезме?

– Уйный идем бугай... – дип исемә төшердем мин. – Нишләргә соң, доктор?

– Берни дә эшләмәскә! Күргәнемчә, сез моңа инде ияләнеп җиткәнсез, менә шулай, авырткан аякка аксап йөрегез... Ә буш кулыгыз калтырамасын өчен, аның белән авыррак сумкаларны йөртегез... Шулай итсәгез, йөрешегез әйбәтләнер... Сәламәт булыгыз!

Мин урамга чыктым һәм анда бераз бөкрәйгән, башларын җилкәләренә батырган, кулларына авыр сумкалар тоткан кешеләрне күрдем... Аларның яхшырак күрер өчен чекрәйгән күзләрендә безнең түләүсез медицинабыз өчен әйтеп бетергесез горурлык балкый иде...




Виктор ФЁДОРОВ


Илдар НӘФИЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Александр ШУЛЬПИНОВ



Дамир МОРТАЗИН

ИЛДӘ ДӘ, ЛИФТТА ДА – ШУЛ!

Әхмәт лифтта бикләнеп калды. "Диспетчер" дигән кнопкага төртүе булды, динамиктан ачулы хатын-кыз тавышы ишетелде.

– Нәрсә килеп чыкты инде сезнең анда?

– Карагыз әле...

– Күрмим бит!

– Лифтымда ябылып калдым!

– Үзегезнекендәме?

– Юк ла инде – государственныйныкында...

– Төгәлрәк әйтеп сөйләгез...

– Бишенче йорт, икенче подъезд...

– Ә-ә, беләм – ипотека йорты. Анда әле түбәдән ага, һәм фасадтан плитәләр коела. Югыйсә күптән түгел генә сафка бастырдылар, инде лифты да эшләми... – дип әйтеп куйды диктофон.

– Әйе, әйе! Нәкъ шулай. Ага да, тама да, коела да... Сез миңа булышырсызмы соң?

– Кара син моны, нинди хәйләкәр! – дип гаҗәпләнде диспетчер. – Бер сәгать тә утырмаган, инде ярдәм сорый...

– Сез диспетчермы, әллә түгелме?! – Әхмәт тавышын күтәрә төште. – Сезнең бурыч бит ул – миңа булышу!

– Ә синең бурыч бу очракта – тыныч кына утыру!

– Аңламадым...

– Шуны да аңламыйсың – башыңны эшләт бераз. Аңлатам: хәзер җиденче йортның лифтында бер хатын бала табып ята. Тугызынчы ае, юләр диген инде, лифтта йөрергә уйлаган... Ашыгыч ярдәм килгәнче барлык көчләр шунда ташланды!

– Монда минем нинди катнашым бар!

– Ничек булмасын? Син бит бала тапмыйсың! Түз – ир бул... һәм башкалар турында уйларга өйрән...

– Нәрсә-ә-ә?! – дип гаҗәпләнеп сүзен сузды Әхмәт.

– Тугызынчы йорттагы лифтта бер компания инде берничә көн юбилей үткәрә – шыңшымыйлар! Ә күрше йортта яшәүче сантехник та синең кебек ябылып калган – унбишенче катта батарея шартлап, бөтен подъезддагылар йөзә. Менә шундый хәл! Синеке әле хәйран...

– Аңлыйм... – дип уфтанып куйды Әхмәт. – Ә күпме көтәргә туры килер?

– Юк, озак түгел! – дигәндәй тынычландырды аны диспетчер. – Менә, кемнәрнедер тоткарларга киткән омончылар бушагач, сиңа да вакыт җитәр..

Михаил ЛАРИЧЕВ




Александр АЛЁШИН



Юрий КУХАРЕНКО



Василий АЛЕКСАНДРОВ



БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Россия тәбәкләрдән (бигрәк тә Татарстаннан) салым акчасын каерып ала, аннары – теш пастасын кысып чыгарырдай итеп, фәлән процентын кире өләшә.

Алмаз Хәмзин: Рашат дус, син бу хәлне теш пасталары белән бутап маташма инде, тот та әйт – талый, диген.

Р. Н.: Телевизор экраннарында Соловьев Кремль сандугачы булып сайрый, Кисилев исә чиле-пешле сәяси песәл болгата...

А. Х.: ...һәм җәмгыятьтә – коточкыч вакыйгалар...

Р. Н.: Сакалыңның озынлыгына караганда, акылың кыскарак булырга да мөмкин.

А. Х.: Акылымның нинди икәнлеген белдертмәс өчен, мин сакал йөртмим.

Р. Н.: Күк йөзен җиде катлы, диләр. Мин аны җитмеш җиде катлы – мәңгелек чиксезлек дип күз алдына китерәм...

А. Х.: Кайчагында күз алдына китерә алмаслык уйлар уйлап ятасың син, Рашат дус – яз шигырьләреңне!

Р. Н.: Теләсә нинди күңелсезлекне оныта белсәк, тиз картаймабыз, Алмаз туган!

А. Х.: Картайталар шул, бәгъзеләр...

Р. Н.: Бер елның түгел, бер көннең кадерен белү кыйммәт, минемчә.

А. Х.: Безнең илдә бигрәк тә!..

Р. Н.: Акчаны дөрес итеп санар өчен дә яхшы бармаклар кирәк.

А. Х.: "Кармакка" эләгәсең килмәсә!..

Р. Н.: Мәхәббәт барлыгына ышанучылар бар, ышанмаучы бар. Боларның кайсысы хаклырак?

А. Х.: Ләкин без түгел!

Р. Н.: Тормыш безгә үзеңне табар өчен түгел, үзеңне "иҗат" итәр өчен бирелгән,

А. Х.: Менә дигән фикер!

Р. Н.: Алкоголиклардан алып күп кенә полководецлар да хатын-кыз өстендә үлгән, диләр. Нәрсә, секс шулкадәр әһәмиятле фактор микәнни?

А. Х.: Монда иң әһәмиятлесе – үлгәннәр...

Р. Н.: Белмисеңме, игезәк бала тапкан аналар өчен икеләтә капитал түләнә микән?

А. Х.: Моның җавабын син Путиннан бел!

Ринат АБЗАЛОВ

ТАНЫЙ АЛМЫЙМ ҮЗЕМНЕ

Бар иде лә чаклар!
Киң болында
"Мине ал" дип тора һәр гөле.
Йөзәр тапкыр бер көн эчендә без
Гашыйк идек, Мәҗнүн шикелле...

...Соңгы вакыт нидер үзгәрде күк,
Таный алмыйм һич тә үземне.
Кызлар күргәч йөрәк шашып типми,
Читкә борам никтер йөземне.
Алтмыш тулды бары...
Яшьлек дәрте
Беркая да, юкса, китмәде –
Әллә магнит кыры тыныч түгел,
Әллә глобаль җылыну хикмәте...



Абау!

ЗУР ЮУ

Санкт-Петербургта өйдә банк оештырган йорт хуҗаларын тоткарлаганнар.Йорт мәшәкатьләре арасында булдыклы хатын-кызлар гражданнарның шикле керемнәрен чистага әйләндергәннәр. Бу максат өчен алар 16 ялган фирма файдаланганнар. Оперативниклар финанс отчётлары документларын һәм печатьләрне кухняның тәрәзә төбендә тапкан. Бизнес шулкадәр уңышлы булып чыккан ки, дүрт ел эчендә банкир ханымнар ярты миллиардка якын «пычрак» акча «юып», комиссиядә 33,5 миллион сум акча эшләгәннәр.

ЕРТЛАЧ УРЛАУ

Ростов өлкәсенең Каменск-Шахтинский шәһәрендә полиция бүлегеннән кеше урлаганнар. Ашот М.ны акча таләп итүдә шикләнеп тоткарлаганнар һәм аны ватанына депортацияләргә әзерләгәннәр. Әмма булышка аның иптәше килгән. Ул полиция формасы киеп бүлеккә үтеп кергән, оператив гамәлләр башкару өчен тоткарланучыны алам, дип белдергән. Полиция хезмәткәреннән бернинди документ та сорамыйча һәм аның үҗәтлегенә бирешеп, шикләнелүчене җибәргәннәр. Дөрес, дуслар ерак китә алмаганнар, бернечә сәгатьтән икесе дә рәшәткә артына эләккән.

КАБЕР ЧЕМПИОНАТЫ

Новосибирскида «Кабер чиксезлеге» дигән исемләнгән тизлеккә кабер казу буенча Бөтенроссия чемпионаты уздырылганган. Эшнең сыйфатын чокырга табут салып тикшергәннәр. Кабер казырга 38 минут вакыт сарыф итеп, Омск командасы җиңүче булган. Оештыручылар мондый ярышлар һөнәрне популярлаштыру һәм зиратка яшьләрне җәлеп итү өчен кирәк дип белдерә.

ЧИК БУЕ ИНЦИДЕНТЫ

Бельгия фермеры очраклы рәвештә Франциягә кечерәйткән. Ул җир сөргәндә, аңа комачаулаган ташны 2,5 метрга күчергән. Әмма таш гадәти генә булмаган – ул Бельгия һәм Франция арасында чикне билгеләгән һәм анда 200 ел, Наполеонның Ватерлоо сугышында җиңелүеннән бирле, торган. Дипломатик җәнҗал булдырмас өчен, фермерга ташны тарихи урынына кире кайтарырга тәкъдим иткәннәр, югыйсә бу мәсьәләне 1930 елдан бирле эшләми торган Франция-Бельгия чик буе комиссиясен тапшырырга туры киләчәк.

Константин ЧАХИРОВ









БАШКА ИЛДӘ

Клуб гомер-гомергә авылның үзенә күрә тормыш үзәге иде – монда һәрвакыт төрле бәйрәмнәр, җыелышлар, концертлар һәм яшьләр өчен дискотекалар уздырылып килде. Ул инде күптәннән төзелгән, тора-бара яраксыз хәлгә килгән иде. Ниһаять аны ремонтлау өчен акча табылды. Ул акчаның күпмесе кая киткәндер, Ходай гына белә, тик шулай да бер ел дигәндә клубны рәткә керттеләр.

Эшләр тәмамлангач, күрсәтергә шәһәр түрәләрен чакырдылар. Концерт әзерләнде. Катгый күрсәтмә җиткерелде: барча катнашучыларга иң шәп киемнәрен киярге, калганнарга, нәчәлникләр алдында авылны уңайсыз хәлгә куймас өчен, клуб тирәсендә уралып йөрмәскә.

Концерт бик шәп узган, җирле талантлар җыр-биюләре белән кунакларны таң калдырганнар. Тәнәфес вакытында бер түрә ханым урамга һава суларга чыккан. Клуб янынан иске шыгырдавык велосипедларга атланып, Бичура белән хатыны узып баралар икән.

– Бу нинди шамакайлар?! – дип чыраен сыткан ханым. Клуб өчен бизәкле йөзлекләр ясап урнаштырган Мирзаһит шул тирәдә маташа икән. Ул аңлатып биргән:

– Бу безнең пенсионерлар...

– Пенсияләре күпме инде аларның? – дип кызыксынган кала кунагы.

– Ун мең тирәсе бардыр, – дип җавап биргән Мирзаһит.

– Сумнар беләнме? – дип гаҗәпләнгән ханым.

– Әйе, сумнар белән – дигән Мирзаһит.

– Алар беркайчан да эшләмәгәннәрдер...

– Юк, үзе гомер буе тракторда җир сөрде, ә хатыны фермада сыер сауды...

– Безнең илдә шундый акчага яшәп буламыни? – дип гаҗәпләнгән түрә ханым.

– Сезнең илдә булмыйдыр, – дигән Мирзаһит, – ә безнекендә бөтенесе дә шулай яши...

Һәм, кулын болгап, өенә таба юнәлгән.


Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ

Максим СМАГИН



Вячеслав ШИЛОВ





Василий АЛЕКСАНДРОВ



АМУР ФӘЛӘХ КЫТЫКЛАРЫ

БӘРӘҢГЕ ҖЫЮЧЫЛАР

Узган гасырның җитмешенче еллары. Ул елларда көз җитүгә мәктәп укучыларын колхоз басуына, бәрәңге-чөгендер җыярга йөртәләр иде.

Балалар өчен, мәктәп классларында сәгатьләр буе дәрестә утыруга караганда, бермә-бер рәхәт, билгеле. Шуңа күрә беренче көннәрдә хәтта "икеле мичкәләре", тәртип ягы чамалы булган укучылар да күмәк эштә бик теләп катнаша. Ләкин тора-бара алар бу бертөрлелектән дә туя һәм эштән качуның төрле ысулларын эзли башлый.

Көннәрдән бер көнне авыл читендәге бәрәңге басуына бардык. Сыйныф җитәкчебез Алмаз абый, бармагы белән төртә-төртә, безне санап чыкты. Ике малай юк: Рафис, Газизҗан.

– Берәрегез беләме, нишләп алар бүген эшкә чыкмаган икән?

Җавап ишетелмәде.

– Ярар, кичкә таба өйләренә сугылып чыгармын, – диде Алмаз абый.

Ә без тракторга тагылган "бәрәңге алгыч" актарып чыгарган бүлбеләрне җыярга керештек.

– Тәк, балалар, мин тиз генә өйгә кайтып киләм, таралмагыз, әнә чиләк каплап бәрәңге пешерегез, – диде Алмаз абый төшке аш ялына тукталгач.

Ашыга-ашыга ихатасына кайтып җитте Алмаз абый. Тиз генә капкалап алды, мал-туарын караштыргач, кече йомышын үтәргә дип, бакча ягындагы бәдрәфкә юнәлде.

Шулчак бакча башындагы алмагачлар янында мәш килүче малай-шалайны шәйләп алды ул. Тавыш-тынсыз гына алар янына атлады. Якынрак килеп караса: көпә-көндез Алмаз абыйның алма бакчасына караклар кергән! Ике малай: Рафис, Газизҗан...

– Һайт! – дип куйды малайлар янына сиздермичә генә килеп баскан Алмаз абый. – Нәрсә, бәрәңге агачта үсәме әллә?

Укытучының бакчасы бер мизгелдә бушап калды. Әбәттән соң эш урынына килсә, ике малай да, берни булмагандай, иптәшләре белән бәрәңге чүпләп йөри...



АВТОБУСТА

Яңа ел төнендә шәһәрнең Үзәк чыршысы янына бәйрәмгә барган идем. Әллә картлык, әллә... Кеше артык күп җыелган урыннарны өнәп бетермим.

Менә бу юлы да килеп ун минут чамасы вакыт үтте микән, андагы тавыштан, петарда шартлатудан бөтен әйләнә-тирәне биләп алган сасы истән кан басымым күтәрелүен тойдым. Тизрәк кайтып китәргә дип, тукталышка юл алдым.

Әле бәйрәмнең башланып килүе генә булгангадыр инде, кайту ягында торучылар әллә ни күп түгел.

Мин яшәгән урамга баручы маршрут автобусы килеп туктады. Салонда утырыр урын булмаса да, басып кайтырга шактый иркен.

Минем янда гына купшы киенгән бер чибәркәй бара. Янәшәсендә баскан килеш бер исерек йокымсырый.

Кинәт ул күзләрен ачты да чибәркәйгә төбәлде.

– Ручкаң бармы?

Башта аптырап калган чибәркәй, бераздан:

– Һәм нәрсәгә инде сиңа ручка? – дип мыскыллы елмайды.

– Телефон номерын язып куй.

Чибәркәй ни әйтергә дә белмәде:

– ?!

Исерек, горур кыяфәттә:

– Тик кара аны, еш шалтыратасы булма!

Һәм янә күзләрен йомды...





• • •

Бакчадагы бәдрәфегезнең тәрәзәсен йөрәк формасында кисеп куймасагыз да була иде бит инде – шулчаклы мәхәббәттән ваз кичтегезмени?!.

• • •

– Доктор, бер тешне суырту күпме тора?
– Мең сум.
– Биш минут эшләгән өчен мең суммы?
– Теләсәгез, бер сәгатькә суза алам.

• • •

– Кадерлем, синең туган көнеңә нәрсә бүләк итим: смартфонмы әллә алкамы?
– Тун бүләк ит һәм бер кесәсендә смартфон булсын, ә икенчесендә – алкалар.

• • •

Егетләр, әгәр күзләре – чия, күкрәге – алма, буй-сыны груша кебек кыз очратсагыз... Бу – мәхәббәт түгел! Бу – сезгә витамин җитми дигән сүз! Җиләк-җимеш ашарга кирәк!

• • •

Бармен танышына сөйли:
– Шулхәтле зур кайгы! Кичә безнең даими клиентыбыз үлде. Әйбәт, бик шәп кеше иде. Һәр көнне алтышар кружка сыра һәм бер шешә аракы эчә иде.
– Нәрсәдән үлгән соң ул?
– Анысын белмим.

• • •

Фермадагы сарыкларга инвентаризация ясау уңышсыз тәмамланды. Көтүнең яртысын санау белән, комиссия һәрчак йокыга тала.

• • •

– Официант, мин бит ике порция ит сораган идем. Ә сез берне генә китергәнсез.
– Гафу итегез. Ашыгып, аны икегә бүләргә онытканмын.

• • •

– Ә сез кайда ял итәргә очасыз?
– Мин очарга куркам шул...
– Сез очар алдыннан курыкмас өчен, бераз эчеп куегыз.
– Эчсәм, миңа монда да рәхәт!

• • •

– Официант, сезнең шницельнең тәме суган кушып тапталган өй тапочкасын хәтерләтә!
– Әй Аллам! Ниләр генә ашарга туры килмәгән икән сезгә үз гомерегездә...

Юрий КУХАРЕНКО



Максим СМАГИН





ӘЙЛӘНДЕРЕП ЙӨРТӘЛӘР

Хөрмәтле редакция! Әлмәт районындагы Яңа Нәдер авылы янында Зәй елгасы аша салынган күпер күптән ремонт ясарлык хәлдә иде. Менә хәзер инде ул, җимерелеп, йөреп булмас рәвешкә керде. Бала-каза килеп чыкканчы аның аркылы чыгу бөтенләй туктатылды, һәм әйләнеп узар өчен билге куйдылар. Әмма Нәдер белән Тайсуган авылы аша әйләнгечтән үтү бер дә җайлы түгел – тар, кыек-мыек, чокыр-чакырлы юл тагын да куркынычрак. Ә машиналар агымы күпер юклыктан һич тә кимеми...

Әлегә күпер салуга тотынган берәү дә юк. Ул шул килеш – җимерек. Ахрысы, аны төзәтергә уйламыйлар да. Түрәләр, бердәм килешеп, уйлаганнардыр – халыкны "әйләнгечтән юл туры" дигән мәкальгә ышандырып, тинтерәтеп маташалар.

Э. ГАЛӘВИН

әлмәт

БАКЧА ВӘХШИЛӘРЕ

Кадерле Чаян! Һәр кешенең авылы турында мактанып сөйләрдәй истәлекле урыннары бар. Безнең Ключида ул атаклы алма бакчасы иде. Аны ике гасыр элек дворян токымындагы хуҗалар утырткан булган. Әйе, аларга рәхмәтебез зур иде...

Күптән түгел билгесез "башкисәрләр" агачлар шау чәчәккә күмелгән вакытта бөтен алмагачларны төпләп-турап чыктылар. Бу бит әле югары мөнбәрләрдән табигатьне саклау турында бертуктаусыз сөйләп торганда һәм тарихи истәлекләрнең әһәмияте, эко-туристлыкны җәелдерү максатларын күздә тотып уйлаганда!

Аңлашыла, мондый кыргыйлык район һәм Казан җитәкчеләренең ризалыгы белән эшләнгәне көн кебек ачык. Кемнәр файдасына бакчаны юк иткәне генә билгесез. Әмма шунысы мәгълүм: зур керем, файда артыннан куып, әлеге бәндәләр бөтен нәрсәне җир белән тигезләргә дә әзерләр. Ямь, гүзәллек, саф һава, хәтер, тарихи кыйммәтләр аларны кызыксындырмый.

Ключи авылы халкы

ЮГАРЫ ОСЛАН районы





Юрий КУХАРЕНКО

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Тормышта булган бөтен шәп нәрсә йә законсыз, йә әхлаксыз, йә симерүгә китерә.

Кешенең ялгышуы табигый, ә ялгышларда башкаларны гаепләү – тагын да табигыйрак.

Сәгате булган кеше төгәл вакытны белә. Сәгатьләре күп булган кеше берни дә белми.

Сездән ике яшькә кечерәк белгеч – тәҗрибәсез, ә биш яшькә өлкәнрәге – заманадан артта калган картлач.

Бу дөньяда күп күрергә теләүчеләр өчен яктылык та, теләмәүчеләр өчен караңгылык та җитәрлек.

Вак мәсьәләләр тиз чишелә, ә әһәмиятлеләре беркайчан да чишелми.

Мәсьәләләр чишүдән ерак кешеләр, гадәттә, югары әхлаклы була.

(Тәҗрибәле хезмәткәрләр мәҗлесендә язып алынды.)



Русларда "Пушкин – наше всё" дигән әйтем бар. Без, татарлар, Тукайга карата нәкъ шул ук сүзләрне әйтә алабыз. Чөнки барыбыз да балачактан аның "Туган тел"ен көйләп, "Шүрәле"сен укып үскән халык. Безнең Тукай ул бөек шагыйрь генә түгел, татар әдәбиятына, шигъриятенә, юмор-сатирасына нигез салучы да, актив җәмәгать эшлеклесе дә.

Ул әдәбиятка беренче рус революциясе елларында, азатлык идеяләре белән рухланган халык җырчысы булып килә. Казанда эшли башлагач, Тукай Г. Камал, Г. Коләхмәтов, Ф. Әмирхан, Х. Ямашев кебек алдынгы интеллигенция вәкилләре белән аралаша, "Әл-Ислах" редакциясендә эшли, "Яшен", "Ялтйолт" сатирик журналларында хезмәттәшлек итә.

Кыска гына гомере эчендә Габдулла Тукай искиткеч бай мирас калдыра, тирән мәгънә һәм ялкынлы хис белән сугарылган күпсанлы әсәрләр тудырырга өлгерә. Ул – үзенең иҗаты белән татар поэзиясе үсешендә яңа эпоха тудырган шәхес.

ШАГЫЙРЬ

Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да, –
Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!
Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;
Күңлемдә көн һаман аяз – һаман да яз,
Шагыйрь күңлендә кыш булмый да кар яумый.

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәбез, сез каласыз!» – дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

КЫЗЫК ГЫЙШЫК

Тирләп, эссе көндә койнырга теләп,
Бер кеше салкын су алды бер чиләк.
Өст-башын салган; вәләкин шикләнә
Су салырга тәнгә, чөнки чиркәнә.
Бер куя җиргә чиләкне, бер тота;
Нишләсен мискен – суык су куркыта.
Күп азаптан соңра гайрәткә килеп,
Суны җилкә аркылы читкә сибеп
Куйды да, – син нечкәләп бер бак сана: –
«Әл дә тәнгә тимәде», – дип шатлана!

Мин моны яздым, бу – гыйшкым миследер;
Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.
Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам –
Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам.
Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим, имеш;
Ут йотып янсам да, сер бирмим, имеш!
Бер шигырь язсам да, ялган кул куям,
Мин сөйгәнне белмәсен дип куркудан.
Тугъры килсәм, сүз сөйлим салкын гына,
Булса да күкрәк тулы ялкын гына.
Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай;
Шәһренә күптән барып җиткән бугай.
Кайда ул миннән җибәрмәк хат-сәлам?!
«Белми китте, күп шөкер», – дип шатланам.

Белми дим дә, бәлки, «белгәндер» әле!
Әллә инде белгәнен белдермәде?
Аңламыйм, төшмим дә аңлау касдына,
Шигъреми җәйдем аягы астына;
Өйнә җиткәнче басып кайтса аңар,
Шагыйре зур илтифатыннан санар.

ПАР АТ

(өзек)

Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан».

Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна:
«Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел берлән
Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

ЕГЕТ ИЛӘ КЫЗ

Егет:

Сөям чүмеч кеби борныңны, җаным,
Гашыйк булдым, тәмам бетте мәҗалым.
Җанашым, аһ, иләк аузыңны үпсәм!
Ни кайгы, инде мин шул чакта үлсәм.

Кыз:

Мәхәббәтсез! Лыгырдый шунда җукны,
Үзеңдә килмәгән җир бер дә җукмы?

Егет:

Ачуланмасана, Гайниҗамалым,
Сине мин кимсетеп әйтмим лә, җаным.
Синең төсле матур кызлар сирәк бит,
Хатын алсаң, иләк, чүмеч кирәк бит.
Сине алсам, чүмечле һәм иләкле
Булам ич – акча туздырмак кирәкми.



Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

ЮЛӘРЛӘР АВЫЛЫ

Сатирик хикәя
(Ахыры. Башы алдагы санда.)

Реклама яхшы эшләде – ул көнне Фазлыяклар өеннән кеше өзелмәде. Кибет янындагы такта исә язулар белән тулды: "Мәтрүшкә сатарга калдыгызмыни инде?.." дип язучыларның авызын Фазлыякларны яклаучыларның фикере томалады: "Пионервожатый зарплатасына яшәп кара син менә!..", "Сатсалар ни, ошамаса алма!", "Аларга да ничектер яшәргә кирәк бит инде..." ише сүзләр бихисап иде. Шулай итеп, һәркемнең иртәсе шушы такта яныннан башлана башлады. Сюрприз ясап, кайбер фотоларны Шәяхмәт төнлә дә элештергәләде.

Совет хөкүмәтен санга сукмыйча, Европачарак яши торган яшь бер гаилә бар иде авылда. Уллары туды. Панасоник дип исем бирделәр. Бәләкәчнең фотосы да пәйда булды тактада. Күз тимәсен дип йөзен зәңгәр изолента астына яшерделәр.

"Панасонигыбызга бүген алты ай...", "Панасоникның алдагы ике теше чыкты...", "Панасоник беренче сүзен әйтте – "окей" диде..."

Бәбигә карата фикерләр агылды гына: "Афәрин!", "Күз тимәсен, бигрәк сөйкемле бала..." ишеләре белән бергә "сездә генә булды инде бала, достали уже!" дигәннәре дә бар иде.

Тиздән Шәяхмәт өлгерә алмый башлады. кулларына фотоаппарат тоттырып, аңа ярдәмгә дүрт малайны беркеттеләр...

Авыл кызды. Көне-төне кибет яныннан китмәделәр. Плотник Садри кушаматы хөрмәтенә тактаны "Стограмм" дип атадылар. Беркөнне тагын бер яңалык булып алды. Әлеге дә баягы Садриның мич кырында, трусик-майкадан гына гармун уйнап утырган фотосы эленде тактага. "Көе ишетелмәгәч, кызык түгел", дип язды берсе. Шундук Вәдүт боерыгы белән такта янына батарейдан эшли торган магнитофон китереп куйдылар. Теләгән һәркем Садриның карлыкканрак тавыш белән "Алмагачлары"на охшаш җыр сузуын тыңлый ала иде.


Көннәр бер-бер артлы сизелми дә узып китте. Габбасның санаторийдан кайтыр вакыты җитте. Кайтты рәис. Кайтты һәм авызын ачып катып калды... Авылны танырлык түгел иде – бөтен урамнарны чүп үләне басып киткән, ашарга сорап фермада сыерлар мөгри, почта ябык, мәктәп ябык, кибет... Стоп!!! Нишли бу халык монда?.. Рәис кашларын җыерып теге әкәмәт тактага якынрак килде. Шәяхмәт анда завклуб Ландышның ире Фәрхәт белән төшкән фотосын элгән һәм үзләренең үтенече буенча фото астына "Ходай бәхетебезне күпсенмәсен..." дип язып маташа иде. Габбас аның кулыннан ручканы йолкып алды:

– Нәрсә бу?.. Кем уйлап тапты моны?! – рәиснең күзләре акайган иде. Әкрен генә парторгны алга төртеп чыгардылар.

– Вәдүт! Корт чаккыры! Нәрсә бу, дим мин сиңа?!.

– Бумы?.. Бу... – дип мыгырданды тегесе. – Садри тактасы бу. Стограмм.

– Бирермен мин сезгә сто граммыгызны! – Габбас җирдә яткан тимер торбаны алып бар көченә тактага китереп орды. – Марш фермага! Марш мәктәпкә! Марш кәнсәләргә! Мин сезнеме?.. Мин сезне... Рәиснең шашынулы чыраеннан өркеп калган халык эш урыннарына ашыкты. Кибет янындагы чирәмдә исә такта, кәгазь кисәкләре, Панасоникның утызлап фотосы гына ятып калды..



Урамда эссе, +34 градус. Алмаз абый битлеген салырга оныткан. Нишләсен?.. "Чаян"га язылуның кызу көннәре бара.

КОНКУРС!

Кадерле дуслар! Туган тел һәм халыклар бердәмлеге елында "Чаян" журналы редакциясе "Чаянча чагу" дип исемләнгән юмористик хикәяләр конкурсы игълан итә.

1 июльдән 2021 елның ахырына кадәр сез редакциягә үзегезнең шаян хикәяләрегезне җибәрәсез. Без, үз чиратыбызда, аларның иң шәпләрен сайлап алабыз, журналда бастырабыз һәм авторларны акчалата призлар белән бүләклибез.

Җиңүчеләр өчен бүләкләр:
беренче урын өчен – 15000 сум;
икенче урын өчен – 10000 сум;
өченче урын өчен – 5000 сум.

Үзегезнең әсәрләрегезне редакциягә җибәргәнче chayan.ru сайтында конкурсның шартлары белән танышыгыз.

Хикәяләрегезне көтеп калабыз! Конкурста уңышлар сезгә!



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 6 (1907) июнь 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 02.06.2021 ел.
Тираж – 3432 Заказ Е-1684

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Иң юмакай хатын?

2. Нәрсә ул тотрыклылык?

3. Адвокат прокурордан нәрсә белән аерыла?

4. Түләүле медицинаның төп максаты нәрсәдә?

5. Хәерчелек ярлылыктан нәрсә белән аерыла?

6. Картлык кайчан башлана?

7. Кешедә һәм түрәдә нәрсә көрәшә?

ЖАВАПЛАР

1. Шәһрезадә. Ул иренә 1001 кич буе әкиятләр сөйләгән... 2. Моннан җиде ел элек сөйләгән мәзәкләрнең әле дә булса көн кадагына сугып торуы. 3. Адвокатны – клиентның киләчәге, прокурорны үткәне кызыксындыра. 4. Көчле авыруны хроник рәвешкә китерү. 5. Хәерчелек – хәер сорау, ярлылык – хәер дә бирә алмау. 6. Бер авырудан терелеп бетканче, икенчесен дәвалый башлагач. 7. Кешедә мәрхәмәтлек белән явызлык көрәшә, ә түрәдә – караклык белән патриотлык.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 5 нче санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«ӘГӘР БЕЛГӘН БУЛСАМ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Н. НИКИТИНА (Чистай р-ны, Чуаш Ялтаны ав.),
Т. НУРГАЛИЕВ (Казан),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Казаннан **Тәлгат НУРГАЛИЕВ!**

Валерий ТАРАСЕНКО





Валерий ТАРАСЕНКО – балык тоту судноларында диңгез гизүче. Шул ук вакытта төп эшеннән аерылмыйча, карикатура иҗатының тирәнлекләренә дә төшенә. Диңгез гизүче Тарасенконы хезмәттәшләре генә белсә, рәссам Тарасенконы бөтен ил белә. Илнең барлык юмористик басмаларында да алты меңнән артык рәсем бастырылган. Даими авторыбызның кабатланмас график стиле «Чаян» укучыларына да яхшы таныш. Валерий күптән түгел түгәрәк датасын билгеләп үтте. Ә бүгенге вернисаж – аңа бездән бүләк!



